**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**31 гыйнвар, 2022 ел** **№ 141**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә нәтиҗәле һәм тәртипкә салынган җирдән файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы, Биектау авыл җирлегенең 2021 елның 13 ноябрендәге, 2021 елның 23 ноябрендәге гавами тыңлаулары нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 17 номерлы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 28 июнендәге 80 номерлы карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисенең урынбасары,
муниципаль район Башлыгының урынбасары Ә.Ш. Шакиров